**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 2 марты № 211/1;

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясе буенча даими пассажирлар һәм багаж ташу муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» 2017 елның 31 гыйнварындагы 118 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 19 июлендәге 631 номерлы үзгәреше белән)

Кама Тамагы муниципаль районы халкының пассажирлар йөртүгә һәм транспорт хезмәтенә ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажларны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законны гамәлгә ашыру хакында» 2015елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлыТатарстан Республикасы законы белән һәм элек формалаштырылган даими йөртүнең яңа маршрутларына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» 2017 елның 31 гыйнварындагы 118 номерлы карарына, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (инфраструктура үсеше, төзекләндерү һәм ТКХ буенча) Р.Р. Баржановка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин